# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында гражданнардан үзара салым кертү турында

**30.10.2020 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (тракторчы белән техниканы арендалау, сыешлыкны арендалау);
-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»).
- Үчәлле авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Җирле әһәмияткә ия булган Үчәлле автомобиль юлларын карап тоту: (Совет, Октябрь урамнары буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).
-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чаптыру буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре күрсәтү.);
- Үчәлле авылы зиратына контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнерлар (бункер), киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру ,нигез салу, коймалар урнаштыру);
- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару (күмү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина